КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 19 апрель г.Казань № 265

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ведомствоара эшче төркем төзү турында» 2016 ел, 14 июль, 477 нче карары белән расланган гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ведомствоара эшче төркем төзү турында» 2016 ел, 14 июль, 477 нче карары белән расланган гражданнарның аерым категорияләрен дарулар белән тәэмин итү өлешендә социаль хезмәтләр җыелмасы белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан В.Г.Шәйхразиевны, Г.Ю.Вафинны, М.З.Шакировны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

Фазлыева Ләйлә Ринат кызын – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарын;

Садыйков Марат Наил улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын;

Гобәйдуллин Әгъзам Самат улын – «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисен (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин